**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Иске Кәкерле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Татар Төкесе торак пунктында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

**30.11.2020 ел** **Татар Төкесе авылы** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Кәкерле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Татар Төкесе торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**2020 елның 30 ноябре**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Татар Төкесе авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге Советының 2009 елның 7 октябрендәге 54/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Татар Төкесе авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә, хисап комиссиясе күрсәтмәләре нигезендә 2020 елның 30 ноябрендә узган тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә төзелде, аның буенча:

Тавыш бирү тәмамлануга гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә 111 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 84, бу торак пункт территориясендә гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә кертелгән гражданнарның 75,68 % ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 84 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде, бу тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның 100% ын тәшкил итә;

«Каршы» позициясе өчен гражданнар җыенында 0 катнашучы тавыш бирде, бу 0 % тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә карар кабул ителде:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Кәкерле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Татар Төкесе торак пунктында гражданнар җыенын 2020 елның 30 ноябрендә узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләре-гамәлдә.

2. «Чүпрәле муниципаль районының Татар Төкесе авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 2021 елда үзара 500 сум салым акчаларын кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:

- Татар Төкесе авылында Колхоз, Центральный, урамнары юлларына вак таш салуны»: мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән.

3. 2021 елда үзара салым акчасын Чүпрәле муниципаль районының Татар Төкесе авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Татар Төкесе авылында Колхоз, Центральный, Совет урамнары юлларына вак таш салырга.

4. Җыен нәтиҗәләрен «Туган як» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Иске Кәкерле авыл җирлеге
башлыгы, халык җыенында
рәислек итүче: Р.Ф. Фаткуллин